**Республика Татарстан**
**СОВЕТ**
**ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Школьная, д. 1,
с. Ляки, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ЛӘКЕ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Мәктәп урамы, 1 йорт,
Ләке авылы, 423366.
Телефон: (85559) 4-66-16
E-mail: Lkn.Sar@tatar.ru


**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 25 нче ноябре** **№ 14**

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» Сарман районы Ләке авыл җирлеге Советының 2020 елның 25 мартындагы 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242_17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору хакында» 2021 елның 1 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Ләке авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Советның 25.03.2020 ел, № 6 карары белән расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)5 статьяның 9 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр өчен физик һәм юридик затлар тарафыннан акчалар түләү өчен кирәкле мәгълүматны, шулай ук Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәрен формалаштыру чыганаклары булган башка түләүләрне «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртип нигезендә дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында дәүләт мәгълүмат системасына тапшыра, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;»

2)5 статьяның 10 пунктындагы 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларын түләү өчен бүлеп бирелгән ассигнованиеләрне куллануның, бюджетның бердәм счетындагы калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, адреслылыгын һәм максатчан характерын тәэмин итә»;

3). 5 статьяның 11 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) җирлек бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының бюджетка керүнең тулылыгын һәм үз вакытында керүен, бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш, контрольдә тотуны гамәлгә ашыра";

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" .PRAVO.TATARSTAN.RU), «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча: https://sarmanovo.tatarstan.ru урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Ләке авыл җирлеге башлыгы Л.И.Шәрипова